Әйләнә-тирә дөнья дәресе, 2 класс

Фирая Сарварова,
Яңа Әлем төп гомуми белем бирү мәктәбенең башлангыч сыйныфлар укытучысы

Тема: Кешеләр культуралы үсемлекләрнең нинди өлешләрен азык итеп кулланалар

Максат:Кешеләрнең азык итеп культуралы үсемлекләрнең нинди өлешләрен куллануын ачыклауга шартлар тудыру.

Бурычлар:
* культуралы үсемлекләрнең төркемнәргә бүленешен һәм үсемлек өлешләрен кабатлау,ныгыту;
*азык буларак үсемлекләрнең нинди өлешләре куллануын ачыклау,өйрәнү;
*эзләнү-тикшеренү эше белән шөгыльләнеп укучыларның танып- белү активлыгын, уйлау сәләтләрен үстерү;
*толерантлык ,дуслык, бер-береңә хөрмәт,ярдәмчеллек сыйфатлары тәрбияләү,парларда,төркемнәрдә эшли белү күнекмәләре булдыруны дәвам итү.

**Предмет нәтиҗәләре:** Үсемлек өлешләрен белү, үсемлекләрнең ашарга яраклы өлешләрен аерып ала белү; анализлаулап, алган белемнәрне проектлаштыра,гомуми нәтиҗә ясый белү.
Универсаль уку гамәлләрен формалаштыру.
**Шәхси**: үзара дуслык, җылылык атмосферасы тудыру; дәрестә актив,тәрбияле,кайгыртучан иптәш булу.
**Метапредмет нәтиҗәләре:**
**Регулятив** : эшчәнлекне планлаштыра,үз алдыңа максат куя,үз фикереңне әйтә белү; нәтиҗә ясау,үз эшчәнлегеңне контрольдә тоту, игътибарлы булу;өйрәнәсе темага туры китереп уку мәсьәләсен кую һәм хәтердә калдыру;
**Танып-белү**: фикерләүне эзлекле итеп башкару, иҗади һәм эзләнүле харатердагы эшләрдә үз ысулыңны булдыру , эзләнүнең төрле ысулларын куллану; өйрәнгәнне тормышта кулланырга өйрәнү.
**Коммуникатив**-укытучы, иптәшләрең белән үзара аңлаша алу,тыңлый белү ; сөйләшү барышында үз фикереңне җиткерә җиткерә алу; алган мәгълүматны куллана белү.

**Материал**: “Әйләнә-тирә дөнья” дәреслеге, 1 нче кисәк,92-93 нче битләр, мөстәкыйль эш дәфтәре, 40 нчы бит.

**Җиһазлау**: парларда, төркемнәрдә эшләү өчен карточкалар,ноутбук,проектор,экран,презентация, таблицалар,яшелчә, җимешләр үзләре).

**Дәрес тибы**:белемнәрне ныгыту һәм яңа белем үзләштерү.
**Дәрес төре**: эзләнүле дәрес –проект.

**Предмет ара бәйләнеш**: рус теле, әдәби уку.

**Эш төре:** Фронталь, индивидуаль, парларда, төркемнәрдә эшләү.

Дәрес барышы

**I.Мотивлаштыру-ориентлаштыру:**

Хәерле көн,яшь табигатьне сөючеләр!Бүген без безне әйләндереп алган дөнья белән танышуыбызны дәвам итәрбез.Яхшы кәеф белән эшебезне башлыйбыз.

**II.Актуальләштерү.**
–Алдагы дәрестә өйрәнгәннәрне искә төшерик.

1. -Нинди үсемлекләр кыргый үсемлекләр, нинди үсемлекләр культуралы үсемлекләр дип атала?

-Культуралы үсемлекләрне ничә төрлегә һәм нинди төркемнәргә бүлдек**?**
**Слайд 2, Слайд 3**

- Бу үсемлекләр кайсы төргә керә**? Слайд 4**

| | | |
|---|---|---|
| Слива | Бодай | Мамык |
| Бөтнек | Тюльпан | Ячмень |
| Бәрәңге | Ромашка | Помидор |
| Җитен | Алма | Фасоль |
| Нарцисс | Кәбестә | Борчак |

2. Һәр укучыга берәр культуралы үсемлекләрнең рәсемнәре бирелә.

Бирем: үсемлекләрне төркемнәргә бүлегез. ( Яшелчәләр.Бөртекле культуралар.Декоратив үсемлекләр. Җиләк- җимешләр .)Укучылар ни өчен бу җавапны сайлаганнарын әйтәләр.

3. -Ни өчен кешеләр культуралы үсемлекләрне үстерәләр? (туклану өчен, тукыма ясау өчен, матурлык өчен, дару өчен).**Слайд 5 Үзбәя.**

**III.Уку мәсәләсен кую.**
-Укучылар ,ә сезнең уйланганыгыз бармы, үсемлекләрнең нинди өлешләрен азык итеп кулланалар икән?

- Миша «Кешеләр яшелчәләрнең бары тик җимешләрен генә ашыйлар.
- Маша - бу җавап белән килешми.
- Ә сез кемнең җавабы белән килешәсез?(килешмисез?).
  Димәк, проблема килеп чыкты. Нишләргә кирәк?

Бүгенге дәрескә уку мәсәләсен куегыз.

**Слайд 6** . “Кешеләр культуралы үсемлекләрнең нинди өлешләрен азык итеп кулланалар?” Уку мәсәләсен кабатлау ( 2 укучы чиратлашып сорау-җавап бирәләр). **Үзбәя.**

**IV.Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1. Үсемлек өлешләрен кабатлау.

Башта үсемлек өлешәрен искә төшереп китик.

**Парларда эш.**

Укучыларга үсемлек өлешләре сүрәтләнгән рәсемнәр өләшеленә, алар үсемлек өлешләрен язарга тиешләр ( аерым биттә язып эшлиләр ,тәмамлагач бер-берсенә бирәләр, бер-берсенең эшен тикшерәләр.)

**Слайд 7** тикшерү.**Үзбәя.**

2. Өлешчә эзләнү эше.

Өстәлләргә яшелчәләр куела.

-Хәзер дәрестә өлешчә тикшеренү-эзләнү эше алып барырбыз. (Һәрбер өстәлдә яшелчәләр).

- Уйлап,күз алдыгызга китереп, өстәлләрегезгә куелган яшелчә үсемлекнең нинди өлеше икәнен ачыклагыз . Нәтиҗәне дәфтәрләрегезгә язып куегыз..

- 2 пар ( 4 укучы) – кәбестә, суган;
- 2пар ( 4укучы) – кыяр, помидор;
- 2пар ( 4 укучы) - кишер, чөгендер;
- 2пар ( 4 укучы)- бәрәңге;

**Парларда эш**. Уйлау өчен вакыт бирелә.

I төркем: **кәбестә, суган.**

-Нинди нәтиҗә ясадыгыз? Нинди өлешен ашыйбыз? (яфрагын)

- Ә бу ( күчәне күрсәтелә) өлеше ничек атала? (Кәбестә күчәне-кочерыжка).

-Ул кәбестәнең нинди өлешенә керә? (сабак)

- Суганның нинди өлешен ашыйбыз? (яфрагын).

- Суганның сабагы бармы? Менә аның сабагы ( суганны ярып күрсәтәм).

Нәтиҗә: Кәбестәнең һәм суганның яфрагын ашыйлар.**Слайд8**

II төркем: **кыяр, помидор.**

-Нинди нәтиҗә ясадыгыз?(Җаваплар)

-Кыяр, помидор ничек үсә?

-Чәчәк урынына нәрсә барлыкка килә?(җимеш)

- Җимеш эчендә нәрсә бар?( Орлык)

-Әйдәгез, тикшереп карыйк? (кисәм)

- Помидор һәм кыярның нинди өлешен кулланабыз икән? ( орлыклы җимешен).**Слайд 9**

III төркем: **Кишер, чөгендер.**

-Кишер һәм чөгендер ничек үсә?

- Яфрагы бармы? (Бар).

- Сабагы бармы? (Бар).

-Сабактан соң нәрсә килә?(Тамыр)

- Димәк, кишер белән чөгендернең кайсы өлешен ашыйбыз? (Тамырын)

- Бу тамырлар башка үсемлекләрнеке кебек түгел, аерылып торалар. Без ул тамырларны азык итеп кулланабыз. Аларны **тамыразык** дип йөртәләр. **Слайд 10.**

IV төркем: **бәрәңге.**

**-** Бәрәңгенең  кайсы  өлешен азык итеп кулланалар? (фаразланган җавап:җимеш яки тамыр).

- Бәрәңге утыртканда, алганда әти-әниләрегезгә булышканыгыз бармы?

- Бәрәңге казыганда, сабагыннан тартсаң ,җир астыннан нәрсә чыга? (Тамыр)

-Димәк,бәрәңгенең тамыры бар?( Әйе).

-Димәк бәрәңге ул тамыр түгел, ә үсемлекнең кайсы өлеше соң? Тамырдан соң нинди өлеш килә? Рәсемнәрегезгә карагыз әле? (Сабак)

-Нәтиҗә ясагыз.Нәрсә ул бәрәңге**? Слайд11.(** Бәрәңге өлешләре  күрсәтелә).

-Бәрәңге ул сабак,ләкин гадәти түгел. Ә формасын үзгәрткән сабак, аны бүлбе (клубень) диләр.Бәрәңге өслегендә батып торган урыннар бар,эчендә күзләр –бөреләр (почки) бар.Күзле бәрәңгене үренте-побег)  диләр.**Слайд 12. Үзбәя.**

***  Физминут (**Буш карточкаларга сорау –җавап язалар. Музыка белән башкарыла **).**


 4. Ә хәзер алган **белемнәрегезне  проектлаштырыгыз.**

Төркемнәрдә эшлиләр. 5 төркемгә 1әр бит,кәбестә,суган,кишер, чөгендер,кыяр,помидор, суган, бәрәңге рәсемнәре бирелә. (Мөстәкыйль  төркемнәрдә эшлиләр).

 5. Проектны яклау.Һәр төркемнән 1 укучы сөйли. (Көтелгән җаваплар: Яшелчәләрнең төрле  өлешләре  азык итеп кулланылганын белдек.Мәсәлән:помидор һәм кыярның җимешен, кәбестә белән суганның сабагын, кишер белән чөгендернең тамырын, бәрәңгенең бүлбесе-сабагы ашарга яраклы икәнен ачыкладык).

Нәтиҗә: Без үсемлекләрнең   яфрагын, җимешен, тамырын, сабагын ашыйбыз.**Слайд13.**

**Яшелчәләр**



| Яфрак | Җимеш | Тамыр | Сабак |
|---|---|---|---|
| ↓ | ↓ | ↓ | ↓ |
| Кәбестә | Помидор | Кишер | Бәрәңге |
| Суган | Кыяр | Чөгендер | |

6. Җимешле үсемлекләрнең кайсы өлешен ашыйлар? **Слайдлар 14,15.**

6. -Бөртекле культураларның нинди өлешләрен ашыйлар? (Орлыгын) **Слайд 16.**

- Кузаклы культураларның нинди өлешләрен ашыйлар? (Орлыгын). **Слайд 17. Үзбәя.**

7.Өстәмә материал (ясмык белән арахис турында**) Слайд 18,19.**

7. “Мужик һәм аю” мультфильмын карау. (Сүзлек эше: вершки-өске өлеш,яфраклар; корешки-корень –тамырлары).

-Әкияттә нинди үсемлекләр турында сүз бара? (Шалкан һәм арыш).

- Шалканның кайсы өлешен ашыйбыз? (Тамырын).

-Арышның кайсы өлешен ашыйлар? (Өске өлешендәге орлыгын).

- Аю белән мужикның ни өчен дуслыклары бетте?

(Мужик аюны алдады,ул аның наданлыгыннан файдаланды.Аю үсемлекләрнең нинди өлешен кулланырга ярамаганлыгын белми.)

- Димәк, бүгенге дәрестә алган белемнәр киләчәктә кирәкме? Ни өчен кирәк? Үзбәя.

**IV. Рефлексия**

1. - Дәрес башланганда үз алдыбызга нинди максат куйган идек?
- Максатыбызга ирештекме?
- Ничек итеп?
2.- Үзегезнең дәрестә эшләвегезне бәяләгез.Билгеләр кую.

V. Өй эше бирү.Мөстәкыйль эш дәфтәреннән № 55,40 бит.

-Ә хәзер дәрес башланганчы булган белемнәрегез белән уң кулыгызны күтәрегез.Хәзер дәрестә алган белемнәрегез белән сул кулыгызны күтәрегез.Ике кулны бергә кушыгыз да дәрестәге эшчәнлегегез өчен үзегезгә рәхмәт белдерегез. Сез искиткеч күп һәм яхшы итеп эшләдегез.Рәхмәт сезгә!